КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 17 апрель г.Казань № 452

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы предприятиеләренең кадрлар белән тәэмин ителешен арттыруга ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 27 май, 366 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы предприятиеләренең кадрлар белән тәэмин ителешен арттыруга ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы предприятиеләренең кадрлар белән тәэмин ителешен арттыруга ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 27 май, 366 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 11 ноябрь, 929 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы предприятиеләренең кадрлар белән тәэмин ителешен арттыруга ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл территорияләре – авыл торак пунктлары, шәһәр тибындагы поселоклар һәм авылара территорияләр (территорияләрендә Татарстан Республикасының административ үзәкләре булган шәһәр округлары составына керүче авыл торак пунктларыннан һәм шәһәр тибындагы поселоклардан тыш). Татарстан Республикасы территориясендә шундый авыл торак пунктлары һәм эшчеләр поселоклары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана;»;

егерме өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«аграр югары уку йорты – урта һөнәри белем бирү, югары белем бирү программаларын, һөнәри белем бирүнең төп программаларын һәм (яисә) өстәмә һөнәри программаларны гамәлгә ашыручы һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы, Ветеринария һәм фитосанитар күзәтчелек федераль хезмәте һәм Балыкчылык буенча федераль агентлык карамагындагы мәгариф оешмасы;

агротехнологик сыйныф – дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында профильле агротехнологик предметларны тирәнтен өйрәнүне күздә тоткан төп гомуми яисә урта гомуми белем бирүнең мәгариф программасын гамәлгә ашырганда белем бирү эшчәнлеген оештыру формасы;

белгечкә кызыксындыру характерындагы түләү - төп проектта катнашучы белгечләр исемлегенә кертелгән белгечкә билгеләнгән стимуллаштыру характерындагы түләү;

укытучыга стимуллаштыру характерындагы түләү - авыл торак пунктында, шәһәр тибындагы поселокта, эшчеләр поселогында яисә 50 меңгә кадәр халкы булган шәһәрдә урнашкан агротехнологик класслары булган мәктәптә профильле агротехнологик предмет буенча укытуны гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәргә (алга таба - укытучы) билгеләнгән стимуллаштыру характерындагы түләү;

төп проект заказчысы – агросәнәгать комплексы өлкәсендәге проектны гамәлгә ашыруга мәгариф оешмасы (фәнни оешма) белән контракт (килешү) төзегән һәм (яисә) агротехнологик класс булдыру проектын гамәлгә ашыруда катнашучы хуҗалык итүче субъект;

гариза бирүче – авыл территорияләрендә эшчәнлек алып баручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре булган яисә авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый үсә торган җиләк-җимеш, җиләк-җимеш, чикләвек, гөмбә, орлыклар һәм «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше һәм (яисә) 7 статьясының 1 өлешендәге 1 пунктының «а» пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлекләрдә күрсәтелгән азык-төлек продукциясенә карый торган урман ресурсларын җитештерүне, һәм аларны эшкәртү продукциясе җитештерүне, беренчел һәм (яисә) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуар яисә оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә оешма (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш);

гариза бирүче-инвестор - мәгариф объектларына чыгымнар тоткан хуҗалык итүче субъект;

модернизацияләнгән объект – субсидия кысаларында чыгымнар башкарылган мәгариф объекты яисә агротехнологик сыйныфлары булган мәктәп;

фәнни оешма – профильле фәнни учреждение һәм (яки) башка фәнни учреждение;

мәгариф оешмасы – аграр югары уку йорты һәм (яки) башка югары уку йорты;

белем объекты – югары белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасы бинасы (төзелеше, корылмасы), реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга һәм (яисә) җиһазларга чыгымнар гамәлгә ашырылган уку корпусларын, уку остаханәләрен, тулай торакларны, ябык типтагы спорт объектларын һәм яссы спорт объектларын, җәмәгать туклануы нокталарын (ашханәләрне), актлар залларын, китапханәләрне дә кертеп;

агросәнәгать комплексы өлкәсендәге проект - агросәнәгать комплексын алдан технологик модернизацияләү һәм инновацион үстерү максатларында хуҗалык итүче субъектлар ихтыяҗлары өчен контракт (килешү) нигезендә мәгариф оешмалары (фәнни оешмалар) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм (яисә) технологик эшләр уздыруны күздә тоткан проект;

агротехнологик сыйныф булдыру проекты – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы әзерләгән методик тәкъдимнәр нигезендә агротехнологик сыйныф булдыру буенча урта һөнәри һәм (яисә) югары белем бирү мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары һәм хуҗалык итүче субъектлар белән берлектә гомуми белем бирү оешмасы гамәлгә ашыра торган чаралар комплексы;

профильле фәнни учреждение – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге буенча федераль хезмәт һәм Балыкчылык федераль агентлыгы карамагында булган фәнни оешма;

профильле агротехнологик предметы – «Авыл хуҗалыгы һәм авыл хуҗалыгы фәннәре» һөнәр, белгечлек һәм мәгариф өлкәсен әзерләү юнәлешләренең берләштерелгән төркемнәре буенча югары белемнең белем бирү программалары буенча белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча укырга кабул ителгәндә укырга керү сынауларга туры килә торган укыту предметы (урман хуҗалыгына, ауга кагылышлы һөнәрләрдән, белгечлекләрдән һәм әзерлек юнәлешләреннән тыш);

агротехнологик сыйныфларыга чыгымнар – авыл торак пунктында, шәһәр тибындагы поселокта, эшчеләр поселогында яки халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрдә урнашкан агротехнологик сыйныфлары булган мәктәпләрдә профильле агротехнологик фәннәр буенча укучыларны әзерләү өчен акчалата формада чагылыш тапкан һәм капиталь ремонт һәм (яисә) җиһазлар, чыгым материаллары, укыту һәм тәрбия чаралары белән тәэмин итүгә документаль расланган чыгымнар;

аграр югары уку йорты студенты – аграр югары уку йортында укыучы Россия Федерациясе гражданны;

башка югару уку йорты студенты – әлеге пунктның бишенче - унберенче абзацларында күрсәтелгән белем бирү программалары буенча башка югары уку йортында укыучы Россия Федерациясе гражданы;

хуҗалык итүче субъект – индивидуаль эшмәкәр яки оешма-хокук формасына бәйсез юридик зат;

агротехнологик сыйныфы булган мәктәп – агротехнологик сыйныф булдыру проектын гамәлгә ашыруда катнашучы гомуми белем бирү оешмасы.»;

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

«, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның «г» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

10 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

20 пунктның җиденче һәм сигезенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

21 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларында «а» – «д» ярдәмче пунктларында» сүзләрен «а» – «в» һәм «г» ярдәмче пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

22 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

32 пунктта:

егерме икенче - егерме җиденче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

илленче абзацта «, модернизацияләү яисә» сүзләрен «һәм (яисә)» сүзләренә алмаштырырга;

61 пунктта:

икенче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «в» – «г» ярдәмче пунктларында» сүзләрен «в» һәм «д» ярдәмче пунктларында» сүзләренә алмаштырырга, «исәп яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

62 пунктның икенче абзацында «в» – «г» ярдәмче пунктларында» сүзләрен «в» һәм «д» ярдәмче пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

63 пунктның икенче абзацында «в» – «г» ярдәмче пунктларында» сүзләрен «в» һәм «д» ярдәмче пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

64 пунктта «в» – «г» ярдәмче пунктларында» сүзләрен «в» һәм «д» ярдәмче пунктларында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин